# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче Түбән Тәкәнеш торак пунктында 2026 елга үзарасалым кертү турында

№ 10

29 октябрь 2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Тәкәнеш торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Түбән Тәкәнеш авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары (хатыны һәм 18 яшькә кадәрге балалары), көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнар кала, 2026 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау, карап тоту: (юлларны ремонтлау һәм кардан чистарту);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау: (урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү).

3.Әлеге карарны Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Җ.Хәмизуллин